
# Б и т к үр к е – к үз,
# Т е л к үрк е – с үз.

(Татар халык мәкале)

**Лениногорск шәһәре 2 нче урта белем бирү мәктәбе**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Галеева Л.З.**



Күгәрченнәр кебек



Алтын куллы



Колак салу



# Фразеологик

# әйтелмәләр



# Лексикологиянең 5 төп тармагы бар:

- ***семасиология***, *ул сүзләрнең мәгънәсен өйрәнә;*
- ***фразеология***, *ул тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә;*
- ***лексикография***, *ул сүзлекләрне өйрәнә;*
- ***ономастика***, *ул ялгызлык исемнәрен өйрәнә;*
- ***этимология***, *ул сүзләрнең тарихын, килеп чыгышын өйрәнә*

# Кагыйдә:

Ике яки берничә сүздән төзелгән, бер күчерелмә мәгънәне аңлата торган сүзтезмә ***фразеологизм***, яки ***фразеологик әйтелмә*** дип атала. Фразеологизмнар сөйләмдә бер мәгънә аңлаталар, бер җөмлә кисәге булалар, аерым кисәкләргә таркалмыйлар.

# Фразеологизмнарны бер сүз белән алыштырып була.



<  Күзгә-күз сөйләшү (икәү)



Акка кара белән (яхшылап кара) >



< Эт белән мәче кебек (ачуланышу)



Тик утыру (эшләмәү)  >

**Ирекле сүзтезмә        Фразеологизм**

борчак сибү >>>

<<<   җим сибү

авызга су кабу   >>>

<<<   алма кабу

<<<  ризык йоту

ут йоту   >>>

<<<   чикләвек вату

баш вату   >>>

# Рус һәм татар фразеологизмнарының охшашлыгы

| | |
|---|---|
| Браться за ум | Трай тибү |
| Пальчики оближешь | Ике тамчы су кебек |
| Кот наплакал | Алып кадәр |
| Полтора Ивана | Борынын салындырган |
| Как две капли воды | Телеңне йотарлык |
| Повесил нос | Энә очы кадәр генә |
| Бить баклуши | Акылга утыру |

# Ситуатив бирем:

## “Тырыш укучы”, “Ялкау укучы”

а) Кош тоткандай, күзләрен йомганчы
су кебек эчә,
түбәсе күккә тиде, җиң сызганып,
ялт иттерде.

б) Сул аяктан, теләр-теләмәс кенә,
йоклап утырды, сай йөзә, борынын
салындырып, бармакка бармак
сукмады.


Мәсәлән:

***Иртә белән ... ... ... ... .***
***Мәктәпкә ул ... ... ... барды.***
***Дәресләрдә ... ... ... .***
***Мәктәптән ... ... ... кайтты.***
***Өйгә кайткач ул ... ... ... .***





# Әдәби әсәрләрдә фразеологизмнар .



**Мисаллар:**

1) Якын аланга җитү белән, таң калабыз.
2) Төлке язын урман тавыклары тирәсендә була, шуңа аның авыз сулары килә.
3) Әле урманда агачларны шартлатып, төнге суыклар мылтык ата.
4) Җәен куяннар ак йоннарын сорыга алыштыра башлыйлар,аннары, шушы сәер төсләре белән куркытып, табан ялтыраталар.

# Бер көнем

Бармакка бармак сукмадым,
Ахры сул аяктан тордым.
Урын-җирне дә җыймыйча,
Мәктәбемә китеп бардым.



Борыным салынган иде,
Очрады, ярый, җан дустым.
Күңел күтәрелде бераз,
“Исәнме!”, дип, кулын кыстым.

Без икәүдән- икәү генә –
Яттан шигырь сөйләп бардык.
Көне буе баш күтәрми,
Җиң сызганып белем алдык.



Судан коры чыктым бүген:
Сорадылар – җавап бирдем.
Сүзгә кесәгә кермичә,
Матур итеп сөйли белдем.



Тел очында торган җавап,
“Эһ” дигәнче, башка килде.
Сүзне сүзгә ялгый белдем
Алдым шулай яхшы билге.

Башым күккә тия язды,
Борын күтәрмәдем ләкин.
“5”ле алгач, кәеф яхшы,
Ал да гөлгә әйләнде көн.

Очып кына кайттым өйгә,
Әниемнең мин уң кулы.
Бөтен савыт-сабаларны
Ялт иттерде үскән улы!

Шайтан аяк сындырырлык
Иде йокы бүлмәсендә.
Трай тибеп эш чыкмас, дип,
Гөл иттердем һәммәсен дә

(Г.Әхтәмова)